**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Рангазарского сельского**
**поселения Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы**
**Рангазар авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2021 елның 12 апреле** **№ 6**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2021 елның 01 февралендагы 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 01 февралендагы 1 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2021 елның 01 февралендагы 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче кушымтада «Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү» юлында хезмәтләр бәясен (сумнарда) 3700,0 ны 3700,80 гә алмаштырырга һәм аны яңа редакциядә әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (sarmanovo.tatarstan.ru) урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Р. Шарипова

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 12 апрелендагы 6 номерлы карарына кушымта (01.02.2021 ел, №1 карар редакциясендә)

2021 елның 01 февраленнан җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәяләре

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәяләре (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3700,80 |
| 3.Мәрхүмнең гәүдәсен (гәүдә өлешләрен) зиратка күчерү | 1336,39 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1387,79 |
| Барлыгы | 6424,98 |